Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Хиҗәмә белән дәвалану

Түбән Кама 2009

بسم الله الرحمن الرحيم

## Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده و نستعينه و نستغفره و نعوذ بالله من شرور أنفسنا و سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له و من يضلل فلا هادي له و أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له و أشهد أن محمدا عبده و رسوله، أما بعد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз – Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл – пәйгамбәребез Мөхәммәднең (ﷺ) юлы. Шушы ике асыл белән өммәтебезнең әүвәлгеләре туры вә хак юлда булдылар. Ул ике асыл, бу дөньяда да, ахирәттә дә кешенең уңышка вә бәхеткә ирешү юлы. Кем дә кем аларга тотынса – туры юлда булды, ә кем алардан ераклашса, читләшсә – ул адашты вә хәсрәткә батты.

**Хиҗәмәнең тел ягыннан булган төшенчәсе:**

Хиҗәмә гарәп сүзе. «Лисән әл-Гарәп» китабының хуҗасы ибен Мәнзур бу сүз хакында болай диде: ***«Хәҗм — суыру. Әйтелә: Бала әнисенең күкрәген имә, яки суыра. Хәҗҗәм — (ул, нәрсә булса да) суыручы...»***

**Истилахи яки атама[1] төшенчәсе:**

Тән тиресен кисеп, суыртып кан чыгаруны — **хиҗәмә** дип әйтәләр.

1 Нәрсәнең дә булса үзенә хаслап кушылган исеме

# Хиҗәмәнең фазыйләтләре һәм аның белән дәвалануга өндәү

عَنْ أَنَسٍ رضى الله عنه مرفوعا: «إِنَّ أَمْثَلَ مَا تَدَاوَيْتُمْ بِهِ الْحِجَامَةُ وَالْقُسْطُ الْبَحْرِيُّ». (البخاري ٥٦٩٦)

Мәгънәсе: Әнәстән ﵁ риваять кылуынча: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезнең өчен иң яхшы дәвалануыгыз — хиҗәмә һәм диңгез кусты[2]».***

Ибен Хәҗәр «әл-Фәтх әл-Бәрий»дә болай диде: «Бу хәдис хиҗәмәнең шәригатебездә рөхсәт ителүен һәм аның белән дәвалануга өндәүне күрсәтә. Бигрәк тә, кемнәр моңа мохтаҗ булса».

عَنِ ابْنِ عُمَرَ ﵁ قَالَ: فَإِنِّى سَمِعْتُ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ يَقُولُ: «الْحِجَامَةُ عَلَى الرِّيقِ أَمْثَلُ وَفِيهِ شِفَاءٌ وَبَرَكَةٌ وَتَزِيدُ فِى الْعَقْلِ وَفِى الْحِفْظِ ...». (سنن ابن ماجه ٣٤٨٧، تحقيق الألباني: حسن)

Мәгънәсе: Ибен Гомәр ﵁ әйтте: Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Ач карынга (ягъни ашаганчы вә эчкәнче) ясалган хиҗәмә бик тә файдалы. Аңарда шифа вә бәрәкәт, һәм ул акылны вә ятлауны арттыра...».***

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﵁ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «إِنْ كَانَ فِى شَىْءٍ مِمَّا تَدَاوَيْتُمْ بِهِ خَيْرٌ فَالْحِجَامَةُ». (أخرجه أبو داود ٣٨٥٧، صحيح)

---

2 Диңгез кусты: төтәгәндә хуш ис чыгара торган агач кисәге яки сумала. Ибен әл-Гарабий, куст ике төрле була ди. Берсе Һиндстанныкы дип атала һәм ул кара, ә икенчесе диңгезнеке һәм ул ак. Аллаһу әгъләм.

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﷺ риваять кылуынча: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хиҗәмә — сезнең дәваланган нәрсәләрегезнең иң хәерлесе».***

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رضي الله عنه عَنِ النَّبِيِّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «الشِّفَاءُ فِي ثَلاَثَةٍ شَرْطَةِ مِحْجَمٍ ، أَوْ شَرْبَةِ عَسَلٍ ، أَوْ كَيَّةٍ بِنَارٍ ، وَأَنْهَى أُمَّتِي عَنِ الْكَيِّ». (البخاري ٥٦٨١)

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﷺ риваять кылуынча: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Шифа өч нәрсәдә: Хиҗәмәдә, бал эчүдә һәм ярага ут белән (тимер) кыздырып басуда. Ләкин, мин өммәтемне ут белән кыздырып басудан тыям!».***

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ үзенең өммәтен хиҗәмә ясатырга өндәде. Чөнки бу дәвалану ысулында, кешеләргә файда бар вә авырулардан саклану чарасы каралган. Әлбәттә, бу өндәү мәҗбүри вә фарыз түгел, ә бәлки мөстәхәб һәм һәркемнең ихтияры вә авыруына караптыр.

## Авыруга нәсыйхәт

عَنْ عَاصِمِ بْنِ عُمَرَ بْنِ قَتَادَةَ قَالَ: جَاءَنَا جَابِرُ بْنُ عَبْدِ اللَّهِ فِى أَهْلِنَا وَرَجُلٌ يَشْتَكِى خُرَاجًا بِهِ أَوْ جِرَاحًا فَقَالَ: مَا تَشْتَكِى؟ قَالَ: خُرَاجٌ بِى قَدْ شَقَّ عَلَىَّ. فَقَالَ: يَا غُلاَمُ ائْتِنِى بِحَجَّامٍ. فَقَالَ لَهُ: مَا تَصْنَعُ بِالْحَجَّامِ يَا أَبَا عَبْدِ اللَّهِ؟ قَالَ: أُرِيدُ أَنْ أُعَلِّقَ فِيهِ مِحْجَمًا. قَالَ: وَاللَّهِ إِنَّ الذُّبَابَ لَيُصِيبُنِى أَوْ يُصِيبُنِى الثَّوْبُ فَيُؤْذِينِى وَيَشُقُّ عَلَىَّ. فَلَمَّا رَأَى تَبَرُّمَهُ مِنْ ذَلِكَ قَالَ: إِنِّى سَمِعْتُ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم يَقُولُ: «إِنْ كَانَ فِى شَىْءٍ مِنْ أَدْوِيَتِكُمْ خَيْرٌ فَفِى شَرْطَةِ مَحْجَمٍ أَوْ شَرْبَةٍ مِنْ عَسَلٍ أَوْ لَذْعَةٍ بِنَارٍ». قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «وَمَا أُحِبُّ أَنْ أَكْتَوِىَ». قَالَ فَجَاءَ بِحَجَّامٍ فَشَرَطَهُ فَذَهَبَ عَنْهُ مَا يَجِدُ.
(مسلم ٢٢٠٥)

Мәгънәсе: Гасыйм бин Гомәр әйтте: Бервакыт безгә Җәбир бин Габдуллаһ килде, һәм шул вакытта ниндидер ир-ат чуаннанмы, җәрәхәттәнме зарлана башлады. Ул аннан: «Нәрсәгә зарланасың?», — дип сорады. Теге ир: «Чуанга. Ул мине бик газаплый», — диде. Җәбир бин Гадуллаһ әйтте: «Әй егет! Хиҗәмә ясаучыны алып кил!». Теге ир аннан: «Әй Әбү Габдуллаһ! Хиҗәмә ясаучы сиңа нәрсәгә кирәк?», — дип сорады. Җәбир аңа: «Авырткан урыныңа хиҗәмә банкасы куясым килә», — диде. Теге ир: «Аллаһ белән ант итәм! Әгәр дә ул урынга чебен яки кием генә тиеп китсә дә, ул мине газаплый вә авырттыра», — диде. Җәбир аның хиҗәмәдән читләшкәнен күреп болай диде: «Хакыйкатьтә, мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Әгәр дә сез дәваланган нәрсәләрнең берәрсендә файда була торган булса,***

***ул да булса хиҗәмә пычагында, яки бал эчүдә, яки ут белән (тимер) кыздырып басуда. Ләкин, мин ут белән кыздырып басуны яратмыйм».*** Гасыйм бин Гомәр дәвам итеп әйтте: «Бераздан хиҗәмә ясаучы килде, һәм өстән генә аның тиресен кисеп канын суыртты. Шуннан соң ул ир-атның зарланган авыруы бетте».

Бухарида (5697) һәм Мөслимдә (2205) килгән икенче риваятьтә Җәбир бин Габдуллаһ (авырып яткан) әл-Муканнәгның[3] хәлен белергә килгәч, аңа: «Син хиҗәмә ясатмый торып, мин урынымнан да кузгалмаячакмын, чөнки мин пәйгамбәребезнең ﷺ: ***«Хакыйкатьтә, хиҗәмәдә шифа»,*** — дип әйткәнен ишеттем диде.

Бу, хөрмәтле сахәбәнең тәбигыйгә булган күркәм нәсыйхәте. Чөнки ул сахәбә хиҗәмәнең барча авырудан да шифа икәнен расүлебездән ﷺ отып алган иде.

Шулай булгач, әгәр дә авыруның хәлен белергә баргач аның хиҗәмәгә мохтаҗлыгын беләбез икән, хиҗәмә белән нәсыйхәт итәргә тиешбез. Чөнки пәйгамбәребезнең ﷺ сүзе хак, һәм ул үзлегеннән һичнәрсә дә әйтми.

(وَمَا يَنْطِقُ عَنِ الْهَوَى ۞ إِنْ هُوَ إِلا وَحْيٌ يُوحَى) النجم: ٤

Мәгънәсе: **«Һәм ул үз белдеге белән сөйләмәс. Аның сөйләгән сүзе фәкать Аллаһтан иңдерелгән вәхийдер».**

3 Ибен Синән (тәбигый)

# Фәрештәләрнең пәйгамбәребезгә ﷺ хиҗәмә белән нәсыйхәте

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ الله عَنْهُ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَا مَرَرْتُ لَيْلَةَ أُسْرِىَ بِى بِمَلإٍ مِنَ الْمَلاَئِكَةِ إِلاَّ كُلُّهُمْ يَقُولُ لِى عَلَيْكَ يَا مُحَمَّدُ بِالْحِجَامَةِ». (سنن ابن ماجه ٣٤٧٧، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мин Исра кылган төндә кайсы гына фәрештәләр төркеме яныннан узсам да, алар миңа: «Әй Мөхәммәд! Сине хиҗәмә белән нәсыйхәт кылабыз», — дип әйтә торган иделәр».***

Ибен Мәҗәһдә (3479 сахих) килгән икенче риваятьтә, пәйгамбәребез ﷺ: ***«Мин Исра кылган төндә кайсы гына фәрештәләр төркеме яныннан узсам да, алар миңа: «Әй Мөхәммәд! Өммәтеңә хиҗәмә белән әмер ит!», — дип әйтә торган иделәр»,*** — диде.

Бу хәдисләр, хиҗәмәдә Раббыбыздан шифа булуына иң зур дәлилләр булып тора. Хәтта, бу замандагы бик сәләтле табибларга да хиҗәмәнең файдалары билгеле булып бетмәскә мөмкин.

Кем дә кем Аллаһка тәвәккәллек кылып, сыгынып, Аннан гына гафу вә сәламәтлек сорап хиҗәмә ясата икән, ул кеше һичшиксез хиҗәмә сәбәпле Раббыбызның теләге белән файда күрәчәк.

## Хиҗәмә ясаучының сыйфатлары

**Беренче:**

Хиҗәмә ясаучы йомшак күңелле, шәфкатьле, хиҗәмә ясала торган урыннарны белүче һәм дә табибчылык фәнен аңларга вә күзалларга тиеш.

عَنْ عَمْرِو بْنِ شُعَيْبٍ عَنْ أَبِيهِ عَنْ جَدِّهِ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَنْ تَطَبَّبَ وَلاَ يُعْلَمُ مِنْهُ طِبٌّ فَهُوَ ضَامِنٌ». (سنن أبى داود ٤٥٨٦، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Гамр бин Шүгайб әтисеннән, бабасыннан риваять кылуынча, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәү дәвалый икән, ә аның элек дәвалаганы билгеле булмаса, ул вакытта бу кеше барча матди җаваплылыкны үз өстенә ала».***

Ягъни, табибчылыкта билгеле булмаган кеше авыруны дәвалап, авыру кеше вафат булса, бу вакытта йолым түләү дәвалаучы һәм аның туганнары өстенә йөкләнә.

**Икенчесе:**

Хатын-кызларга хиҗәмә ясаучы аның мәхрәме яки инде бәлагатькәирешмәгән яшүсмер булырга тиеш.

عَنْ جَابِرٍ رضي الله عنه أَنَّ أُمَّ سَلَمَةَ اسْتَأْذَنَتْ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ فِى الْحِجَامَةِ فَأَمَرَ النَّبِىُّ ﷺ أَبَا طَيْبَةَ أَنْ يَحْجُمَهَا، قَالَ: حَسِبْتُ أَنَّهُ قَالَ: كَانَ أَخَاهَا مِنَ الرَّضَاعَةِ أَوْ غُلاَمًا لَمْ يَحْتَلِمْ. (مسلم ٢٢٠٦)

Мәгънәсе: Җәбирдән ﵁: **Үммү Сәләмәһ[4] пәйгамбәребездән ﷺ хиҗәмә ясатырга рөхсәт сорагач, пәйгамбәребез ﷺ Әбү Тайбәгә хиҗәмә ясарга кушты. Әйтте: «Әбү Тайбә Үммү Сәләмәһнең имчәктәше яки бәлагатькә ирешмәгән яшүсмер иде».**

## Мәсьәлә

Әгәр дә хатын-кызның хиҗәмәгә хаҗәте булып, ә инде ясаучы мәхрәме дә, хатын-кыз да яки бәлагатькә ирешмәгән яшүсмер дә булмаса, бу вакытта аңа нишләргә?

Бу вакытта табиб булган чит ир-ат аны дәвалый ала. Ләкин хатын-кызның барча тәне дә капланган булып, иллә-мәгәр дәваласы урыны гына тиешлечә ачыла.

عن قتادة قال: قلت لجابر بن زيد: «المرأة ينكسر منها الفخذ أو الذراع، أجبره؟». قال: «نعم». (مصنف ابن أبي شيبة، إسناده صحيح)

Мәгънәсе: Катәдә әйтте: ***«Мин Җәбир бин Зәйдтән: «Әгәр дә хатын-кызның аягы яки кулы сынса, мин аның сынган урынына кабык[5] яки тугым[6] куя аламмы?», — дип сорагач, ул миңа: «Әйе», — диде».***

Ибен Мүфлих «әл-Әдәб әш-Шәргыя»дә болай диде: «Әл-Кадый Гыядъ әйтте: «Табиб кеше (дәвалаганда) хатын-кызның гауратенә зарури булган очракта карый ала, моңа әл-Мәрузийнең, Хәрбнең һәм әл-Әсрамнең риваятьләре ишарәтли. Шулай ук хатын-кыз да, ир-ат та зарури вакытта чит ир-атның гауратенә карый алалар, моңа Хәрбнең һәм әл-Мәрузийнең риваятьләре ишарәтли».

4 Пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны
5 Русча; лубок
6 Русча; шин

## Хиҗәмә ясау өчен яхшырак көннәр

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﷺ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلمِ: «مَنِ احْتَجَمَ لِسَبْعَ عَشْرَةَ وَتِسْعَ عَشْرَةَ وَإِحْدَى وَعِشْرِينَ كَانَ شِفَاءً مِنْ كُلِّ دَاءٍ». (سنن أبى داود ٣٨٦١، تحقيق الألباني: حسن)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем унҗидесе, унтугызы яки егерме бере[7] хиҗәмә ясата икән, бу аңа барча авырулардан да шифа була».***

Бу көннәрнең яхшырак булуына пәйгамбәребезнең дә ﷺ ошбу көннәрдә үзенә хиҗәмә ясатканлыгы күрсәтә.

عَنْ أَنَس ﷺ قَالَ: «كَانَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم يَحْتَجِمُ فِى الأَخْدَعَيْنِ وَالْكَاهِلِ وَكَانَ يَحْتَجِمُ لِسَبْعَ عَشْرَةَ وَتِسْعَ عَشْرَةَ وَإِحْدَى وَعِشْرِينَ». (سنن الترمذي ٢٠٥١، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Әнәс ﷺ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ унҗидесе, унтугызы һәм егерме беренче көннәрдә муен тамырларына һәм муен умырткасының җиденче баганасына хиҗәмә ясата торган иде».***

Ибен әл-Кайим «әт-Тыйб ән-Нәбәүий» китабында бу көннәр хакында болай дип әйтеп узды: «Айның уртасында һәм уртасыннан соң килгән көннәрдә хиҗәмә ясату яхшырак. Кыскасы, айның дүрттән өченче өлешендә. Чөнки, айның беренче өлешендә кан әле ярсымаган һәм хәрәкәтләнмәгән була. Ахыргы өлешендә, кан инде тынычланган була. Ә инде айның уртасында һәм уртасын-

7 Һижри тәкъвим буенча (Ислам календары)

нан соң килгән көннәрдә, канның иң арткан вә иң ярсыган чагы була».

Хәзерге заман тикшеренүләре дә, кан белән айның тулган вакытында бик тә тыгыз элемтә бар дип исбатлыйлар. Кешенең шәһвәтләре вә җинаятькә бирелүләре айның тулган вакытында арта дип бәян кылалар. Аллаһу әгъләм.

Ә инде көннең кайсы сәгатендә яхшырак дигәндә, моны расүлебезнең ﷺ түбәндәге хәдисеннән аңларга мөмкин.

عَنْ صَخْرٍ الْغَامِدِيِّ ﵁ عَنِ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «اللَّهُمَّ بَارِكْ لأُمَّتِى فِى بُكُورِهَا». وَكَانَ إِذَا بَعَثَ سَرِيَّةً أَوْ جَيْشًا بَعَثَهُمْ فِى أَوَّلِ النَّهَارِ. وَكَانَ صَخْرٌ رَجُلاً تَاجِرًا وَكَانَ يَبْعَثُ تِجَارَتَهُ مِنْ أَوَّلِ النَّهَارِ فَأَثْرَى وَكَثُرَ مَالُهُ. (سنن أبى داود ٢٦٠٦، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Сахр әл-Гамидийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Йә Аллаһ! Минем өммәтемнең иртән эшләнгән гамәлләрен бәрәкәтле кыл!»***. Шулай ук, әгәр дә пәйгамбәребез ﷺ гаскәр яки бер төркем сугышчылар җибәрә торган булса, иртәнге якта җибәрә иде. Сахр әл-Гамидий сәүдәгәр иде, һәм сәүдәсен иртә белән башлый торган иде. Ул шулай баеп китте вә аның мал-мөлкәте артты.

## Хиҗәмә ясау урыннары

**1 – Башның уртасына:**

عَنِ عَبْد اللَّه بْنِ بُحَيْنَةَ رَضِىَ اللهُ عَنْهُ قَالَ: «احْتَجَمَ النَّبِىُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ وَهْوَ مُحْرِمٌ بِلَحْىِ جَمَلٍ فِى وَسَطِ رَأْسِهِ». (البخاري ١٨٣٦)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Бүхәйнәһ ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ихрамда вакытта «Ләхий Җәмәл»[8] дигән урынга җиткәч башының уртасына җиҗәмә ясатты».***

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِىَ اللهُ عَنْهُما: «أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ احْتَجَمَ وَهْوَ مُحْرِمٌ فِى رَأْسِهِ مِنْ شَقِيقَةٍ كَانَتْ بِهِ» (البخاري ٥٧٠١)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Габбас ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ихрамда вакытта башына, башы авыртканлыктан хиҗәмә ясатты».***

**2 – Муен тамырларына һәм муен умырткасының җиденче баганасына:**

عَنْ أَنَسٍ ﵁ قَالَ: «كَانَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم يَحْتَجِمُ فِى الأَخْدَعَيْنِ وَالْكَاهِلِ...». (سنن الترمذي ٢٠٥١، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Әнәс ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ муен тамырларына һәм муен умырткасының җиденче баганасына хиҗәмә ясата торган иде».***

---

8 Мәккә белән Мәдинә арасындагы, Мәдинәгә якынрак булган билгеле урынның исеме

**3 – Башның иң югары өлешенә һәм ике калак сөяге арасына:**

عَنْ أَبِى كَبْشَةَ الأَنْمَارِىِّ: أَنَّ النَّبِىَّ صلى الله عليه وسلم كَانَ يَحْتَجِمُ عَلَى هَامَتِهِ وَبَيْنَ كَتِفَيْهِ وَهُوَ يَقُولُ «مَنْ أَهْرَاقَ مِنْ هَذِهِ الدِّمَاءِ فَلاَ يَضُرُّهُ أَنْ لاَ يَتَدَاوَى بِشَىْءٍ لِشَىْءٍ». (سنن أبى داود ٣٨٥٩، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Әбү Кәбшәһ әл-Әнмәрий әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ башының иң югары өлешенә һәм ике калак сөяге арасына хиҗәмә ясата иде, һәм әйтә иде: ***«Кем дә кем бу каннарны агызса, һәм башка авыруларга башка төрле дарулар белән дәваланмаса, аңа зыян килмәс».***

**4 – Лепкәгә[9]:**

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ ﷺ أَنَّ أَبَا هِنْدٍ حَجَمَ النَّبِىَّ ﷺ فِى الْيَافُوخِ فَقَالَ النَّبِىُّ ﷺ: «يَا بَنِى بَيَاضَةَ أَنْكِحُوا أَبَا هِنْدٍ وَانْكِحُوا إِلَيْهِ». قَالَ: «وَإِنْ كَانَ فِى شَىْءٍ مِمَّا تَدَاوَوْنَ بِهِ خَيْرٌ فَالْحِجَامَةُ». (سنن أبى داود ٢١٠٢، تحقيق الألباني: حسن)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﷺ: «Әбү Һинд пәйгамбәребезнең ﷺ лепкәсенә хиҗәмә ясагач, расүлебез ﷺ болай диде: ***«Әй Бәнү Бәядаһ! Әбү һиндка кызларыгызны өйләндерегез, һәм аңа да (ягъни, кызларына) никахланыгыз!».*** Шуннан соң дәвам итеп: ***«Әгәр дә сез дәваланган нәрсәләрнең берәрсендә файда була торган булса, ул да булса хиҗәмәдә»,*** — диде».

**5 – Аяк табанының өске ягына:**

عَنْ أَنَسٍ ﷺ: «أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ احْتَجَمَ وَهُوَ مُحْرِمٌ عَلَى ظَهْرِ الْقَدَمِ مِنْ وَجَعٍ كَانَ بِهِ». (سنن أبى داود ١٨٣٧، تحقيق الألباني: صحيح)

---


9 Яшь баланың маңгайдан өстәрәк, уртада, баш түбәсенә кадәрге йомшак булып торган урыны; русчасы: темя. Гомумән, башның түбәсе белән маңгай арасындагы өлеше

Мәгънәсе: Әнәс ؓ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ихрамда вакытта аяк табанының өске өлешендә авырту булганлыктан, шунда хиҗәмә ясатты».***


Нәсәидә (2849 сахих) килгән икенче риваятьтә: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ихрамда вакытта аяк табанының өске өлешенә, сеңере тартылу сәбәпле хиҗәмә ясатты»,*** — диелде.

Гыйлем ияләре әйтеп узуынча, бу хәдисләрдән күренгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ хаҗәткә вә авыртуларга карап тәненең төрле урыннарына хиҗәмә ясаткан. Шулай булгач, кеше үзенең ихтыяҗыннан чыгып, кайсы урыны авырта торган булса шунда хиҗәмә ясата ала. Бу фикерләрне ибен әл-Кайим «Зәд әл-Мәгад»тә, әт-Табарий «Тәһзиб әл-Әсәр»дә әйтеп узалар.


***Искәрмә: Түбәндә киләсе хиҗәмә белән дәвалану нокталарына карата авыру төрләрен, барысына да аңлаешлы булсын өчен, без урысча искә алып үтәргә булдык.***


114
116
115
118
117
119
120
136
135
133
134
121
122
123
124
137
139
138
142
140
141
143
126
125


**Алгы як**


44
42
40
41
43
1
20
21
46
55
45
47
5
4
48
19
49
6
23
22
50
8
7
10
9
15
25
18
24
14
13
11
12
16
17
27
26
31
30
29
28
52
51


**Арткы як**





Арттан




Алдан





Сул як




Уң як

# Баштагы нокталар




## Кул-аяк

**Группа (А)**

* Ревматизм (болезненные суставы) (точки 1, 55, совместно с непосредственным болезненным участком).

* ‘Тугоподвижность‘ колена (точки 1, 55, 11, 12, 13 и вокруг колена, также можно добавить 53, 54).

* Отёк (Oedema) (скопление избыточного количества жидкости в тканях-водянка ) (точки 1, 55, 130, правая и левая сторона стопы, также можно добавить 9,10).

* Седалищные боли (боли нервов от ягодицы вниз по ноге)

(для правой ноги) (точки 1, 55, 11, 12, 26, 51 и места боли на ноге, в особенности, в начале и в конце мышцы);

(для левой ноги) (точки 1, 55, 11, 13, 27, 52 и места боли на ноге, в особенности, в начале и в конце мышцы).

* Боль в спине (точки 1, 55 и приложение банок по обе стороне спины и в местах ,причиняющих боль)

* Шея/боль в плече (точки 1,55, 40, 20, 21 и места боли).

* Подагра (вспухание суставов в результате излишка мочевой кислоты) (точки 1, 55, 28, 29, 30, 31, 121 и места, причиняющие боль).

* Ревматоидный артрит (точки 1, 55, 120, 49, 36 и все большие и малые суставы).

* Паралич половины туловища (Гемиплегия) (точки 1, 55, 11, 12, 13, 34 или 35, и все поврежденные суставы, массажировать ежедневно).

* Паралич всех четырех конечностей ( Квадриплегия ) (точки 1, 55, 11, 12, 13, 34, 35, 36 и все суставы, ежедневный массаж)

* Иммунодефицит (точки 1, 55, 120, 49).

Мышечный спазм – несколько сухих приложений банок вокруг поврежденной мышцы.

* Слабое кровообращение (точки 1, 55, 11 и 10 банок по обе стороны спины с начала до конца, принимать одну ложку яблочного уксуса и мед через день).

* Синдром дрожащих рук (точки 1, 55, 40, 20, 21, мышцы руки и поврежденные суставы).

* Покалывание в ногах (или синдром дрожащих ног) (точки 1, 55, 11, 12, 13, 26, 27, суставы ноги и поврежденные мышцы).

* Боли в брюшной полости (точки 1, 55, 7, 8 и наложение банок сухим методом на точки 137, 138, 139, 140, также как и сухих банок на противоположной стороны спины от места боли).

**Группа (B)**

Важное примечание: Следующие точки расположены по степени их важности. Терапевт, проводящий лечение, может не использовать все точки и иногда он/ она может использовать их все. В зависимости от состояния больного.

* Геморрой (отекшие сосуды вокруг ануса) (точки 1, 55, 121, 11, 6 и наложение сухих банок на 137, 138, 139).

* Анальный свищ (фистула) (открытие в кожном покрове рядом с анусом, вследствии формирования канала, через который протекает жидкость) (точки 1, 55, 6, 11, 12, 13 и наложение банок вокруг ануса и сверху свища)

* Простатит и неспособность к эрекции,дисфункция эрекции (ДЭ)(мужская импотенция и проблемы при мочеиспускании, вследствии увеличения простаты) (точки 1, 55, 6, 11, 12, 13) и можно добавить для ДЭ 125, 126, 131 на обеих ногах, и наложение сухих банок на 140, 143).

* Хронический кашель и болезни легких (точки 1, 55, 4, 5, 120, 49, 115, 116, 9,10, 117, 118, 135, 136 и две банки ниже обоих колен).

* Гипертензия (повышенное кровяное давление) (точки 1, 55, 2, 3, 11, 12, 13, 101, 32, 6, 48, 9, 10, 7, 8, также можно заменить точки 2, 3 точками 43, 44).

* Проблемы с желудком и язвы (точки 1,55, 7, 8,50, 41, 42 и наложение сухих банок на 137, 138, 139, 140).

* Болезни почек (точки 1, 55, 9, 10, 41, 42 и сухие банки на 137, 140).

* Синдром раздраженного кишечника (боли в брюшной полости и дискомфорт, отличительные признаки: вздутие живота, метеоризм, чередующийся приступами поноса и запора, зачастую вследствии тревоги) (точки 1. 55, 6, 48, 7, 8, 14, 15, 16, 15, 16, 17, 18, 45, 46 и сухую банку на 137).

* Хронический запор (трудности калоотделения в течении длительного времени) (точки 1, 55, 11, 12, 13, 28, 29, 30, 31).

* Понос (сухие банки на 137, 138, 139, 140).

* Непроизвольное мочеиспускание (энурез,писанье в постель) (после пяти лет: сухие банки на 137, 138, 139, 140, 142, 143, 125, 126).

* Депрессия, отчуждение, инсомния(бессонница), психологические отклонения и нервозность (точки 1,55, 6, 11, 32 и под коленками).

* Ангиоспазм (сосудистый спазм) и артериосклероз ( точки 1, 55, 11) (накладывать банки в местах боли, через день принимать яблочный уксус и мед).

* Воспаление слизистой оболочки желудка (гастрит) (точки 1, 55, 121).

* Чрезмерный сон (точки 1, 55, 36), кроме того, чайная ложка яблочного уксуса и меда через день.

* Пищевые аллергии (одна сухая банка (без кровопускания) прямо на пупок, легкое присасывание).

* Раны, абсцессы ног и бедер (гнойники) и зуд подвздошной впадины (зуд в области бедра) (точки 1, 55, 129, 120).

**Группа (С)**

Важное примечание: Следующие точки расположены по степени их важности. Терапевт, проводящий лечение, может не использовать все точки и иногда он/ она может использовать их все. В зависимости от состояния больного.

* Болезни сердца ( точки 1, 55, 19, 119, 7, 8, 46, 46, 47, 133, 134).

* Диабет (точки 1, 55, 6, 7, 8, 22, 23, 24, 25, 120, 49), примечание: область кровопускания должна смазываться маслом черного тмина и медом в течение 3 дней.

* Печень и болезнь желчного пузыря ( точки 1, 55, 6, 48, 41, 42, 46, 51, 122, 123, 124 и 5 чашек справа, внешняя сторона ноги).

* Варикозные вены (увеличенные, неприглядные поверхностные вены) на ногах (точки 1, 55, 28, 29, 30, 31, 132 и вокруг вен, но не по венам).

* Варикоцеле (увеличенные вены на мошонке мужчины) (точки 1, 55, 6, 11, 12, 13, 28, 29, 30, 31, 125, 126).

* Слоновая болезнь (раздутая нога из-за блокировки каналов лимфы);

примечание: пациент должен отдохнуть в течение 2 дней перед кровопусканием. Он или она должен также

поднять его/ее больную ногу и затем поместить в теплую воду в течение двух часов до кровопускания (точки 1, 55, 11, 12, 13, 120, 49, 121 и вокруг затронутой ноги от вершины ноги к основанию в дополнение к 125, 126, 53, 54).

* Кожные заболевания (точки 1, 55, 49, 120, 129, 6, 7, 8, 11 и кровопускание на зонах поражения).

* Избыточный вес (точки 1, 55, 9, 10, 120, 49 и области желательной потери веса), ежедневно массаж по области желательной потери веса.

*Недостаток веса ( точки 1, 55, 121).

* Целлюлит: ежедневно массаж по проблемной зоне.

* Бесплодие ( точки 1, 55, 6, 11, 12, 13, 120, 49, 125, 126, 143, 41, 42 ).

* Болезнь щитовидной железы (точки 1, 55, 41, 42).

**Группа (D)**

*Головные боли (точки 1, 55, 2, 3) и Вы можете заменить точки 2, 3 на 43, 44.

- Если это вызвано чрезмерным напряжением зрения, добавляют 104, 105 и 36. Если это вызвано носовыми пазухами, добавляют 102, 103 и 114.

Если это вызвано высоким кровяным давлением, добавляют 11, 101 и 32.

Если это вызвано запором, добавляют 28, 29, 30 и 31.

Если это вызвано холодом, добавляют 120, 4 и 5.

Если это вызвано болью живота, добавляют 7, 8.

Если это вызвано почками, добавляют 9, 10.

Если это вызвано желчным пузырем и печенью добавляют 6, 48.

Если это вызвано позвонками позвоночного столба, выполняют кровопускание на позвоночник.

Если это вызвано напряженностью, добавляют 6, 11 и 32.

Если это вызвано анемией, добавляют 120, 49 и берут одну чайную ложку черного меда (патока) с четвертью столовой ложки фенугрека (араб. хильба) и 7 черн. тмина ежедневно .

Если головная боль происходит из-за опухолей в мозге,кровопускание должно быть выполнено на области боли на голове.

*Мигрень (серьезная головная боль, связанная с тошнотой и визуальными нарушениями) (точки 1, 55, 2, 3, 106 и область боли).

*Болезни глаз (сетчатка, глазная некоординированность, затуманенное зрение, атрофия глазных нервов, глаукома , катаракта и слабый глаз, глазное воспаление и слезотечение и чувствительность глаз (точки 1, 55, 36, 101, 104, 105, 9, 10, 34, 35, выше бровей и на линии волос выше лба).

*Миндалины, горло, десна,зубы, и проблемы среднего уха (головокружение, тошнота и звон в ушах ) (точки 1, 55, 20, 21, 41, 42, 120, 49, 114, 43, 44).

*Слабость слуха и воспаление ушного нерва, звон в ушах ( точки 1, 55, 20, 21, 37, 38 и позади уха).

*Носовые пазухи (точки 1, 55, 102, 103, 108, 109, 36, 14 и на линии волос).

*Неврит (воспаление) пятого и седьмого нервов (точки 1, 55, 110, 111, 112, 113, 114 и на зоне поражения).

*Для стимуляции системы восприятия (повышает понимание) ( точки 1, 55, 2, 3, 32).

*Клиническая потеря памяти (важно: если делают кровопускание точки 39 излишне,то это может вызвать потерю памяти. Также его ненужное повторение может привести к потери памяти ( точка 39- затылочный бугор).

*Немота (неспособность говорить) (точки 1, 55, 36, 33, 107, 114 ).

*Чтобы помочь прекратить курить (точки 1, 55, 106, 11, 32 ).

*Конвульсия (судороги) (точки 1, 55, 101, 36, 32, 107 с обеих сторон, 114, 11, 12, 13).

*Для лечения задержки умственного развития (точки 1, 55, (101 только 1 р.) 36, 32, 2, 3, 120, 49, 11, 12, 13 ).

*Атрофия (потеря) мозговых клеток (кислородный дефицит) (точки 1, 55, 101, 36, 32, 34, 35, 11 и выполняют кровопускание на суставах, мускулах и шее, 43 и 44 на передней и задней части. Съешьте мед и королевское желе. Выполняйте кровопускание ежедневно).

**Группа (Е) Гинекологическая**

*Геморрагия (влагалищное кровотечение) (точки 1, 55, (3 сухих чашки под каждой грудью ежедневно, пока кровотечение не прекратится).

*Аменорея (отсутствие периодов) (точки 1, 55, 129, (131 от внешней стороны), 135, 136).

*Мажущие коричневые выделения- 3 сухих чашки под каждой грудью ежедневно до прекращения (точки 1, 55, 120, 49, 11, 12, 13 и 143). Если у выделений нет никакого запаха, цвета или зуда, кровопускание на точки 1, 55, 9, 10, 41, 42, 11, 12, 13, 143.

*Менструальные проблемы (точки 1, 55 (сухое, без кровопускания – на точки 125, 126, 137, 138, 139, 140, 141, 142, 143).

*Для стимуляции яичников (точки 1, 55, 11, (сухое, без кровопускания – на точки 125, 126).

*Боль после маточной операции, ежемесячная менструальная боль, проблемы закрытия фаллопиевых труб (перевязанная/непроходимая труба), наличие молока в груди, не будучи беременными, и менопаузальные признаки (депрессия, нервозность, психологические состояния ..) ( точки 1, 55, 6, 48, 11, 12, 13, 120, 49) (Сухое, без кровопускания – на точки 125, 126).

## Ибен әл-Кайим һәм табиблар искә алган файдалар

1 – Тәннең өске өлешен вә тире катламасын тазарта.

2 – Муен умырткасының җиденче баганасына хиҗәмә ясату иңбаш һәм тамак авыртуларыннан файдалы.

3 – Әгәр дә канның ярсуы яки бозылуы белән бәйле булып баш, бит, теш, колак, күз, борын һәм тамак авыртулары сизелсә, ул вакытта муен тамырларына хиҗәмә ясату файдалы була.

4 – Ияк астына хиҗәмә ясату, әгәр дә вакытында кулланылса, теш, бит һәм тамак авыруларыннан файдалы. Шулай ук, башны һәм казналыкларны тазарта вә сафландыра.

5 – Аяк табанының өске ягына хиҗәмә ясату тубык янындагы зур кан тамырын пакьли, аяк авыруннан файдалы. Шулай ук, хатын-кызларның күрем каны өзелүеннән файдалы.

6 – Күкрәкнең аскы өлешенә хиҗәмә ясату тиредәге вә тәндәге шеш авыруларыннан, чуаннан, буын авыруларыннан, фил чиреннән һәм тән кашыну чирләреннән файдалы.

Хакыйкатьтә, хиҗәмә иләһи дәва. Авыруның хәленә, урынына вә вакытына карап тиешлечә кулланылса, ул һичшиксез, Аллаһның теләге белән, хәзерге заман дәвалау ысуллары гаҗиз булган бик күп авырулардан дәва булып тора.

## Хиҗәмә уразаны бозамы?

Ураза тотучының хиҗәмә ясауы вә ясатуы белән бәйле хәдисләр ике төрле.

**Беренчесе:**

Хиҗәмә ясаучының да, ясатучының да уразасы бозыла.

عَنْ ثَوْبَانَ الْهَاشِمي رَضِيَ الله عَنْهُ عَنِ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وسَلَّمَ قَالَ: «أَفْطَرَ الْحَاجِمُ وَالْمَحْجُومُ». (سنن أبى داود ٢٣٦٧، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Сәүбән әл-Һәшимийдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хиҗәмә ясаучы да, ясатучы да уразаларын боздылар».***

Шушы ук мәгънәдәге хәдисләрне пәйгамбәребездән ﷺ ундүрт кеше риваять кыла: Сәүбән, Шәддәд бин Әүс, Рафигь бин Хадиҗ, Әбү Һүрайраһ, Гаишә, Биләл, Үсәмә бин Зәйд, Гали бин Әбий Талиб, Сәгъд бин Әбий Үаккас, Әбү Зәйд әл-Әнсарий, Әбү Мүса әл-Әшгарий, ибен Габбас, ибен Гомәр һәм Мүгькыйл бин Синән.

Бу хәдисләрнең күпчелеге зәгыйфь. Әбү Гыйсә әт-Тирмизий Гали бин әл-Мәдинийдән риваять итүенчә болай диде: «Бу мәсъәләдә иң дөрес хәдисләр Сәүбәннән һәм Шәддәд бин Әүстән риваять ителә». Дәвам итеп: «Мин Бухаридән сорадым, ул: «Бу мәсъәләгә кагылган хәдисләрдә Сәүбән һәм Шәддәд бин Әүснекеннән дә дөресрәк хәдисләр юк...», — диде.

Беренче караш хәдисләрен Гали бин Әбий Талиб, Әбү Мүса әл-Әшгарий, ибен Гомәр (ахырдан, чөнки ул әүвәл рөхсәт итүне хуп күрә иде), Гата бин Әбий Рабәх, Мәсрук, әл-Хәсән, ибен Сирин, Габдуррахман бин Мәһдий, әл-Әүзәгый, Әхмәд бин Хәнбәл, Исхак бин Раһәүәйһ, Әбү Бәкер бин әл-Мүнзир һәм ибен Хүзәймәһләр хуплады.

**Икенчесе:**

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ رضى الله عنهما قَالَ: «احْتَجَمَ النَّبِيُّ صلى الله عليه وسلم وَهُوَ صَائِمٌ». (البخاري ١٩٣٩)

Мәгънәсе: Ибен Габбас ﵁ әйтте: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ураза хәлендә хиҗәмә ясатты».***

عَنْ ثَابِت الْبُنَانِىّ أَنَّهُ سَأَلَ أَنَسَ بْن مَالِك رَضِىَ الله عَنْهُ: «أَكُنْتُمْ تَكْرَهُونَ الْحِجَامَةَ لِلصَّائِمِ». قَالَ: «لا، إِلاَّ مِنْ أَجْلِ الضَّعْفِ». (البخاري ١٩٤٠)

Мәгънәсе: Сәбит әл-Бүнәний Әнәс бин Мәликтән ﵁: ***«Сез ураза тотучыга хиҗәмә ясатуны тыя идегезме?», — дип сорагач, ул аңа: «Юк, иллә-мәгәр хәлсезлектән генә»,*** — диде.

Ураза вакытында хиҗәмәне рөхсәт итеп килгән хәдисләр ибен Габбастан, Әнәстән һәм Әбү Сәгыйд әл-Худрийдән риваять ителә.

Шулай итеп, хиҗәмә уразаны бозмый дигән карашны Сәгъд бин Әбий Үаккас, Габдуллаһ бин Мәсгуд, Габдуллаһ бин Габбас, Әнәс бин Мәлик, Әбү Сәгыйд әл-Худрий, Хөсәен бин Гали, Зәйд бин Аркам, Гаишә, Үммү Сәләмәһ, Гурүә бин Зүбәйр, Касыйм бин Мөхәммәд, Сәлим бин Габдуллаһ, әш-Шәгьбий, Сәгыйд бин Җүбәйр, Мүҗәһид һәм Тауслар хуплады.

Шулай ук, бу Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигыйларның карашы. Аллаһу әгъләм.

# Аллаһ сынаган махау авырулы, пеләш һәм сукыр кыйссасы

Әбү Һүрайрадан ﵁ риваять кылуынча, ул пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишетте: ***«Аллаһ тәгалә (кайчандыр) бәни Исраилдән булган өч кешене; махау авырулыны, пеләшне һәм сукырны сынауга дучар итәргә теләде. Аллаһ тәгалә махау авыруы белән авыручы янына фәрештәне җибәрде һәм: «Син бөтен нәрсәдән дә артыграк нәрсә телисең?», — дип сорады. Ул әйтте: «Яхшы төс, яхшы тире һәм кешеләр миннән кача торган нәрсәнең миннән китүен телим». Шунда фәрештә аны (кулы белән) сыпырды, аның авыруы китте, һәм ул (янәдән) яхшы төстә һәм яхшы тиредә булды. (Аннан соң фәрештә): «Ә сиңа нинди мөлкәт бөтен нәрсәдән дә артыграк ошый?», — дип сорады. Ул: «Дөяләр» (яки: ... сыерлар), — дип җавап бирде, һәм аңа буаз дөя бирелде, (шуннан соң фәрештә): «Аллаһы Тәгалә бу дөяне синең өчен бәрәкәтле итсен!» — диде. Аннан соң (фәрештә) пеләш кеше янына килеп: «Бөтен нәрсәдән дә артыграк нәрсә телисең?» — дип сорады. Ул: «Яхшы чәч һәм кешеләрнең миннән качуына сәбәп булган нәрсәнең миннән китүен телим», — диде. Шунда фәрештә аны (кулы белән) сыпырды, һәм ул (янә) яхшы чәчле булды. (Соңыннан фәрештә): «Сиңа бөтен нәрсәдән дә артыграк нинди мал ошый?», — дип сорады. Ул: «Сыерлар», — диде. Аңа буаз сыер бирелде, (шуннан соң фәрештә): «Аллаһы Тәгалә бу сыерны синең өчен бәрәкәтле итсен!» — диде. Аннан соң (фәрештә) сукыр янына килеп: «Син бөтен нәрсәдән дә артыграк нәрсә телисең?», — дип сорады. Ул: «Аллаһы Тәгаләнең миңа күзләремне кайтаруын һәм кешеләрне күрергә телим», — диде. Шунда фәрештә аны (кулы белән) сыпырды, һәм Аллаһы Тәгалә аңа күзләрен кайтарды. (Соңыннан фәрештә): «Сиңа бөтен нәрсәдән дә артыграк нинди мал ошый?» — дип сорады. Ул: «Сарыклар», — диде. Аңа буаз сарык бирелде. Бу***

*хәлдән соң (дөя белән сыер) үрчем бирделәр һәм (сарык та) үрчем бирде, ә беркүпме вакыттан соң (аларның) берсенең үзәнлек тулы дөяләре, икенчесенең — үзәнлек тулы сыерлары, өченчесенең — үзәнлек тулы сарыклары булды. Аннан соң (фәрештә элеккеге махау авырулы кеше) янына аның (әүвәлге) сурәтендә килде һәм аңа: «Мин фәкыйрь кеше, һәм юлда малымнан мәхрүм булдым, бүген минем Аллаһыдан башка, ә (Аңардан) соң сиңа (ярдәм сорап) мөрәҗәгать итәрлек беркемем дә юк. Сиңа яхшы төс һәм яхшы тире, мал бирүче Зат белән ялварам, (миңа) дөя (бир), мин шул дөя ярдәмендә сәфәремне тәмамлар идем!», — диде. (Бу кеше җавап биреп: «Минем) бурычларым күп», — диде. (Шунда фәрештә): «Мин сине беләм бит. Син махау авырулы идең, һәм кешеләр синнән качалар иде түгелме? (һәм син) фәкыйрь булып, Аллаһы Тәгалә сиңа (мал) биргән кеше түгелме соң?», — диде. (Бу кеше): «Дөреслектә, мин бу байлыкны бабаларымнан мирас итеп алдым», — диде. (Шунда фәрештә): «Әгәр син алдаган булсаң, Аллаһ сине әүвәлге сурәтеңә кайтарсын!», — диде. Аннан (фәрештә элек) пеләш булган кеше янына, аның әүвәлге сурәтендә килде, һәм аңа да (элек махау авырулы булган) кешегә әйткәннәрне әйтте, ә бу кеше аңа шундый ук җавап биргәч, аңа да: «Әгәр син ялганласаң, Аллаһы Тәгалә сине әүвәлге сурәтеңә кайтарсын!», — диде. (Аннан фәрештә элек) сукыр булган кеше янына, аның әүвәлге сурәтендә килде һәм аңа: «Мин фәкыйрь юлчы, һәм мин сәфәр кылганда малымнан мәхрүм калдым, бүген минем Аллаһыдан башка, ә (Аңардан) соң сиңа (ярдәм сорап) мөрәҗәгать итәрлек беркемем дә юк. Синнән күзләреңне кайтарган Зат белән ялварып сорыйм, (миңа бер) сарыгыңны бир, ул минем сәфәремне тәмамларга җитәр!», — диде. (Элек сукыр булган кеше): «Мин дөрестән дә сукыр идем, ә Аллаһ миңа күзләремне кайтарды, нәрсә теләсәң шуны ал, һәм нәрсә теләсәң, шуны калдыр. Аллаһ белән ант итәм, бар нәрсәгә кодрәтле һәм олуг Аллаһ ризалыгы өчен, син нәрсә генә алсаң да, бүген мин сине бернәрсә белән дә мәшәкатьләмимм!», — диде. (Фәрештә): «Малыңны үзеңә калдыр, чөнки, дөреслектә, сезне бары тик сынауга гына дучар иттеләр, һәм Аллаһ синнән разый булды, ә синең ике дустыңа Ул ачуланды», — диде».* (Бохари, Мөслим)

# Эчтәлек


Кереш сүз..........................................................2

Хиҗәмәнең фазыйләтләре һәм аның белән дәвалануга өндәү..........................................................3

Авыруга нәсыйхәт..........................................................5

Фәрештәләрнең пәйгамбәребезгә ﷺ хиҗәмә белән нәсыйхәте..........................................................7

Хиҗәмә ясаучының сыйфатлары..........................................................8

Мәсьәлә..........................................................9

Хиҗәмә ясау өчен яхшырак көннәр..........................................................10

Хиҗәмә ясау урыннары..........................................................12

Ибен әл-Кайим һәм табиблар искә алган файдалар...27

Хиҗәмә уразаны бозамы?..........................................................28

Аллаһ тәгалә сынаган махау авырулы, пеләш һәм сукыр хикәясе..........................................................30